

**1 июльдә, Иске Кулаткы районында, милли бәйрәмебез - Сабантуй үтәчәк.**

# КҮМӘК КӨЧ


ГОМУМИ РАЙОН ТАТАР ГАЗЕТАСЫ
1930 елдан чыга.
Бәясе ирекле
№ 24 (10716)
Чәршәмбе,
14 июнь 2017 ел.
(Атнага бер тапкыр чыга)

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫЛАР: 1. УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕ ХӨКҮМӘТЕ (432017, Ульяновск шәһәре, Ленин мәйданы, 1). 2. "ИСКЕ КУЛАТКЫ РАЙОНЫ" МУНИЦИПАЛЬ БЕРЛӘШМӘСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ (433940, Ульяновск өлкәсе, Иске Кулаткы эшчеләр бистәсе, Пионерская урамы, 30)




**18 июнь - Россиядә медицина хезмәткәрләре көне**

**Хөрмәтле сәламәтлек саклау өлкәсе хезмәткәрләре һәм әлеге тармакта эшләгән ветераннар!**

Медицина хезмәткәрләре – иң мактаулы һөнәр ияләре. Райондашларыбыз, үзәк хастаханәдә, фельдшер-акушерлык пунктларында күптөрле авырулардан дәва алып, профилактика үтеп, сәламәтлекләрен ныгыталар. Авыруларның савыгып аякка басуы, райондашларыбызның яхшы кәефе, житештерүчән эшләве, гомер озынлыгы ак халатлы шәфкать ияләренең үз һөнәрләрен күңел биреп, намус белән башкаруына турыдан-туры бәйле.

Игелекле хезмәтегез – кешеләр сәламәтлеген һәм гомерен саклау - шәфкатьлелек, түземлек, тырышлык, шул ук вакытта зур җаваплылык таләп итә. Сезгә һөнәри осталыгыгыз, фидакарь хезмәтегез өчен рәхмәтебезне җиткерәбез! Барыгызга да ныклы сәламәтлек, аяз күк йөзе, гаилә бәхете һәм игелекле гамәлләр кылу өчен шәфкатьлелек телибез.

**Э.Ә. ГАНЕЕВ,**
**Иске Кулаткы район Башлыгы, урындагы “Бердәм Россия” партиясенең политсовет Секретаре.**
**И.А. АБЛЯЗОВ,**
**Иске Кулаткы районы администрациясе Башлыгы.**

## Илебезнең иң мөһим бәйрәме



12 июнь – Россия көне. Бу көн 1994 елда Россиянең беренче Президенты Борис Ельцин тарафыннан тәкъдим ителә. Баштарак бәйрәм Бәйсезлек көне дип аталса, 2002 елдан, гадиләштереп, Россия көне дип йөртелә башлый.

Кайда гына яшәсәк тә, нинди генә телдә сөйләшсәк тә, без бербөтен күпмилләтле Россия халкын тәшкил итәбез. Барыбызның да Ватаны бер. Бу бәйрәм дә туган илебезгә мәхәббәт, горурлык хисләрен арттыра.

(Дәвамы 2 биттә).

## Бөтен авыл сөенде



10 июнь көнне Бахтеевка авылында чуваш халкының милли бәйрәме - Акатуй гөрләп үтте. Көне дә искиткеч матур, кояшлы, җылы булды. Бәйрәм авылның үзәгендә, мәктәпнең спорт мәйданында булды. Урын аулак, спорт ярышларына да, сәүдәгә дә. Үзәктә, иң хөрмәтле урында, зур итеп сәхнә корылган. Акатуйга район җитәкчеләре, авылның яше-карты җыелды. Аларны стадион капкасыннан ук моңлы чуваш көйләре, матур иттереп бизәлгән мәйданчыклар, чуваш халкының гореф-гадәтләрен чагылдырган авыл йорты, сату нокталары каршы алды.

Акатуй бәйрәмен башлау үзенчәлекле иде. Милли киемнәр киенгән мәдәният хезмәткәрләре сәхнә түренә узып, кадерле, олы кунакларны каравай белән сыйладылар һәм түгәрәккә алып әйлән-бәйлән йөределәр.

Милли бәйрәмнең тантаналы өлешендә район администрациясе Башлыгы И.А. Аблязов, аның урынбасары И.Ш. Мәгдиев, район Атакае Илья Арланов сәламләп, бәйрәмгә килгән кунакларны Акатуй белән котладылар, күңелле ял итүләрен теләделәр. Бүләкләү тантанасында алдынгы хезмәткәрләр, үрнәк гаиләләр хөрмәтләнде.

Милли көрәш, уеннар музыкаль чыгышлар белән үрелеп барды.

Бәйрәм көне буе дәвам итте. Авыл халкы, килгән кунаклар бер-берсе белән аралашып, күңел ачтылар.

**Әлфия ЯФАРОВА.**

## РАМАЗАН АЕ - ИФТАРЛАР, АВЫЗ АЧУЛАР АЕ



Көн озын булуга карамастан, изге Рамазан аенда мөселманнар ураза тота. Әлеге айда ифтар мәҗлесләре үткәрү күркәм һәм бик тә саваплы гамәлләрдән санала. Пәйгамбәребез: «Рамазан аенда ризык арта. Кем бер ураза тотучыга авыз ачтыра, аның бу эше гөнаһлары кичерелүгә, тәне уттан котылуга сәбәп була. Ураза тотучыга уразасы өчен күпме әҗер булса, аңа да шул кадәр савап була. Моның белән ураза тотучының әҗере һич кимемәс», - дип өммәтен юмартлыкка чакырды.

Иске Кулаткы район Башлыгы Э.Ә. Ганеевның тырышлыгы белән һәр ел район мәчетләрендә ифтар мәҗлесләре уздыру - күркәм традициягә әйләнде. 8 – 9 июнь көннәрендә үзәк "Җәмигъ" мәчетендә генә һәр көн саен 250 кешелек табын әзерләнде. Авыз ачып, ахшам намазын укыганнан соң, мөселманнар мул табын артында Аллаһының ризалыгын өмет итеп, тәмледән - тәмле ризыклар белән сыйланды. Сүз уңаенда шуны да әйтеп узарга кирәк, үзәк мәчеттәге ифтар ашларын әзерләүдә пешекчеләрнең зур тырышлыклары игътибарга һәм хөрмәткә лаек.

Биредә имамнар, мөгаллимәләр вәгазьләр сөйләделәр, догалар кылдылар. Э.Ә. Ганеев биргән хаерларны халык мәчеткә калдыруны хуп күрде. Барысы да шатланып, пакъланып, рәхмәтләр укып таралышты.

**Майзә МАСИЕВА.**

| ПӘНҖЕШӘМБЕ (15.06.) | ҖОМГА (16.06.) | ШИМБӘ (17.06.) | ЯКШӘМБЕ (18.06.) | ДҮШӘМБЕ (19.06.) | СИШӘМБЕ (20.06.) | ЧӘРШӘМБЕ (21.06.) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| + 22 | + 21 | + 17 | + 21 | + 23 | + 20 | + 21 |
| + 12 | + 11 | + 12 | + 12 | + 13 | + 10 | + 11 |

## ЯҢАЛЫКЛАР



Россия Президенты В.В. Путин Кремльдә үткән тантанада кунакларны Россия көне белән котлады. Ул яшь граждannарга – төрле конкурсларда, олимпиадаларда, ярышларда, акцияләрдә җиңүчеләргә паспортлар тапшырды. Шулай ук медицина, мәдәният, фән өлкәләрен үстерүдә зур өлеш кертүче шәхесләргә Хөкүмәт премияләрен тапшырды.

● ● ●

Шанхай хезмәттәшлек оешмасы саммиты кысаларында Россия Президенты Владимир Путинның Ислам Республикасы - Пакистанның Премьер-министры Наваз Шариф белән очрашуы үтте. Ил Башлыклары ике яклы хезмәттәшлек итү мәсьәләләре, сәүдә - икътисади мөнәсәбәтләрнең үсүе, халыкара мәсьәләләр буенча фикер алыштылар.

● ● ●

“Россиянең көньяк төбәкләре һәм Үзәк Азия - террорчыларның алдынгы максатлары булырга мөмкин”, - дип ассызыклады ил Башлыгы Владимир Путин. Бу хакта ул Астанада, Шанхай хезмәттәшлек оешмасы саммиты кысаларында үткән лидерлар очрашуында сөйләде. Шуңа күрә ул очрашуда катнашучыларга araларны ныгыту, терроризм мәсьәләсен игътибарда тоту кирәклеген билгеләде.



2017 елда Ульяновск өлкәсендә бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт хакын арттыруга якынча 700 миллион сумм акча юнәлдереләчәк. "Халыкның яшәү дәрәҗәсен күтәрүне тәэмин итү - региональ хакимиятнең төп бурычы булып кала. Моңа беренче чиратта лаеклы хезмәт хакы тәэсир итә. Россия Президентының Май указларының берсе дә шуңа багышланган. Соңгы өч елда хезмәт хакын арттыруга без 3,1 млрд. сум акча юнәлдердек. Билгеле, бу берникадәр нәтиҗәләр дә бирде. 2017 һәм алдагы елларда без әлеге дәүләт бурычын үтәүне дәвам итәрбез. Моның өчен Ульяновск өлкәсендә барлык ресурслар да бар", - дип ассызыклады Сергей Морозов.

● ● ●

Ульяновск өлкәсе Губернаторы Сергей Морозов 12 июнь – Россия көнендә, “Мәктәпкә җыенырга ярдәм ит!” хәйрия акциясенә старт бирде.

● ● ●

РФ Хөкүмәте рәисе Дмитрий Медведев 7 июнь көнне эшлекле сәфәр белән Ульяновск өлкәсендә булды. Губернатор Сергей Морозов аңа регионның альтернатив энергетика өлкәсендәге проектларын тәкъдим итте. Дмитрий Медведев өлкәбездә илебездә беренче җил паркының куәтлеген арттыру инициативасын хуплады.

## Дорогие россияне!

Поздравляю вас с Днём России! Этот праздник знаменуют многовековой, непрерывный путь нашей Родины, достижения и победы, переломные, судьбоносные этапы и неизменный подъем к новым высотам развития. Главная заслуга в возрождении страны, в укреплении государства всегда принадлежит ее гражданам, их труду, сплоченности, преданности Отчизне. Мы знаем об этом не только из истории.

Кардинальные преобразования 90-х изменили жизнь современных поколений. Мы сами прошли через этот сложный, драматически период. Радикальное обновление коснулось тогда всех ветвей и уровней власти, экономических и общественных отношений. Перемены такого масштаба и такой глубины всегда имеют разные последствия. Россия, наш народ пережили не только стремительный прорыв к новому, а без этого невозможно развитие, так оно и было, но и крайне опасное, тревожное время ослабления государственности, размытости, уязвимости общественных устоев.

Но все эти трудности были преодолены. Год за годом наряду с развитием демократических институтов, повышением уровня открытости общества приходило осознание значимости собственных корней и традиций, понимание, что можно идти вперед только в крепкой, самостоятельной, независимой стране и что силу государства обеспечивают политическая стабильность, единство целей и консолидация общества.

Всем вместе нам удалось сохранить уникальное многообразие народа России, не допустить забвения и девальвации принципов гражданственности и патриотизма, надежно укрепить суверенитет своей страны, четко обозначить национальные интересы России. Мы научились их твердо отстаивать, опираясь, в том числе на исторический опыт. И эта цельность восприятия России – наше важнейшее достояние.Дорогие друзья! Для того, чтобы добиться успехов в экономике, социальном развитии, мы должны понимать, слышать и уважать друг друга, дорожить тем, что уже удалось сделать для Родины, для повышения качества жизни людей, их безопасности. Нам всем надо ориентироваться на позитивную, созидательную повестку. Каждому по силам внести свой вклад в укрепление России. В этом наш долг перед Отечеством, наша ответственность за его настоящее и за будущее нашей Родины.

С праздником! С Днём России!

**Президент РФ В. В. ПУТИН.**

## Уважаемые жители Ульяновской области, дорогие земляки! От всей души поздравляю вас с одним из главных государственных и общенародных праздников – Днём России!

К этой дате принято вдумчиво анализировать промежуточные итоги года. И сегодня Ульяновская область подошла к этому рубежу с хорошими результатами. У нас отмечается уверенный рост экономики, динамично развивается первая в России портовая особая экономическая зона, куда приходят новые резиденты. Открываются предприятия в промышленной зоне «Заволжье», растут в нашем крае индустриальные и технопарки, в том числе и детский - один из первых в стране. Недавно в регионе открылся мировой гигант - завод «Бриджстоун», также дебютировавший в Российской Федерации. Достижения Ульяновской области в сфере инвестиций и инноваций, создания благоприятного делового климата вызвали большой интерес участников крупнейшего в мире события начала лета – Петербургского международного экономического форума. Об этом красноречиво свидетельствуют масштабные контракты с крупнейшими фирмами планеты. Всё это – фундамент для дальнейшего быстрого развития нашей малой родины, продолжения активной социальной и демографической политики, создания новых рабочих мест, строительства современного доступного жилья, школ, детских садов, решения проблем ульяновцев.

Дорогие друзья! В этот праздничный день желаю вам большого счастья, семейного благополучия, крепкого здоровья! Совместными усилиями будем и дальше благоустраивать нашу землю для поколений сегодняшнего и завтрашнего дня!

**Губернатор Ульяновской области С.И. МОРОЗОВ.**

## МО МВД России «Павловский» информирует:

В целях профилактики и предупреждения правонарушений несовершеннолетних, защите их прав и законных интересов в УМВД России по Ульяновской области 21 июня, 19 июля, 16 августа в период с 15.00 до 16.00 часов будет организована прямая линия по вопросам профилактики совершения преступлений и правонарушений несовершеннолетними по телефону: (8-8422) 67-87-74.



## ☎ ПРЯМАЯ ЛИНИЯ

У вас есть вопросы к полиции?

Уважаемые жители Старокулаткинского района!

16 июня проводится «прямая линия» с начальником Межмуниципального отдела МВД России «Павловский» подполковником полиции Александром Юрьевичем Рябовым. Вы можете задать свои вопросы по телефону: 8 (84-248) 2-15-94 с 15 до 17 часов.

# Илебезнең иң мөһим бәйрәме



Россия көне уңаеннан районыбызда да күптөрле чаралар узды. Бәйрәм программасы 11 июнь көнне районыбызның үзәк мәйданында көндезге 14.00 сәгатьтә Воронеж шәһәреннән килгән халык исемен йөрткән “Горница” казак коллективының чыгышы белән башланып китте. Аларның дәртле биюләре һәм җырлары райондашларыбызга бәйрәм кәефе бүләк итте. 12 июнь көнне район мәдәният йорты каршында Россия көне уңаеннан тантаналы чара үткәрелде. Әлеге чарада районыбызның оешма, предприятие, төрле учреждениеләр, мәктәп һәм балалар бакчалары коллективлары, килгән кунаклар катнашты. Бәйрәм тантаналы төстә Россия әләмен күтәрү церемониясеннән башланды. Аны башкару өчен Иске Кулаткы беренче һәм икенче номерлы урта мәктәпләренең уку алдынгылары һәм укытучылары чакырылды. Иске Кулаткы район Башлыгының урынбасары, район Советы депутаты М. М. Бәширов райондашларына Россия Президенты В.В. Путинның, район Башлыгы Э.Ә. Ганеевның бәйрәм котлауларын җиткерде һәм хезмәт алдынгыларына Ульяновск өлкәсе Губернаторы исеменнән Рәхмәт хатларын тапшырды. Район администрациясе Башлыгы И. А. Аблязов өлкә Губернаторы С.И. Морозовның һәм үзенең бәйрәм котлауларын җиткерде һәм Халыкара олимпиадаларда, конкурсларда катнашып, җиңү яулап кайткан укучыларга һәм укытучыларга Дипломнар һәм Рәхмәт хатлары, яшүсмерләргә паспортлар тапшырды. Бәйрәм трибунасыннан Бердәм Россия партиясенең урындагы башкарма комитеты җитәкчесе Л. Р. Амирова да чыгыш ясады һәм райондашларыбызны илебезнең патриотлары булырга өндәде. Бәйрәм программасы балаларның һәм район мәдәният йорты хезмәткәрләренең матур җырлары һәм кичке күңел ачу программасы белән дәвам итте. Тарихыбыз безне күп нәрсәгә, шул исәптән, дөньядагы көчле дәүләт урынын яулап алу



һәм үзенең бәйсезлеген раслау өчен, Россиянең күпгасырлык авыр юл үткәнен онытмаска да өйрәтә. Әйдәгез, үз казанышларыбызның да, ата-бабаларыбыз казанышларының да кадерен белеп яшик.

**Гөлназ КУЗӘЕВА.**

# Мәсьәләләр хәл ителде

Күптән түгел генә район администрациясендә Иске Кулаткы Гаделлек палатасы һәм җәмәгать контроле палатасының чираттагы утырышы булып үтте. Аны палатаның рәисе Р. М. Байбикова алып барды.

Утырышта район мәгариф бүлеге мөдире Ф. З. Зайнетдинова җәйге каникуллар вакытында балаларның ял итүләре турында чыгыш ясады.

- Быел безнең районга ятим балаларга ял итү өчен 44 путевка бирелә. Ләкин һава торышының әлегә салкын булуы сәбәпле, аның срогы бераз алгарак күчерелә. Балалар Николаевка районының “Ак күл” ендә, Татарстан республикасының “Бүләк”, “Дуслык” һәм өлкәбезнең лагерларында рәхәтләнеп ял итәчәкләр. Шуның белән беррәттән 15 июньнән палатка лагеры эшләячәк.

Укучыларның ял итүләре турында шулай ук Иске Кулаткы район балаларга өстәмә белем бирү үзәге директоры Р. Н. Кузәев та чыгыш ясады. Ул җәйге чорда белем бирү үзәгендәге һәм балалар паркында ял итү планнары белән таныштырды. Шуның белән бергә балалар паркында махсус музыкаль аппаратураларны эшләтү өчен уңай шартлар булдыру яисә электр челтәре ноктасы кирәклеге турында да искәртелде.

Утырышта шулай ук балаларның юл куркынычсызлыгы турында сүз җитди барды һәм моның буенча аларга даими инструктажлар үткәрү кирәклеге белдерелде. Шушы нигездә Иске Кулаткы эшчеләр поселогы эченнән зур йөкле техникаларны әйләнеш юлдан йөрүләре турында таләп ителде. Бу мәсьәләне чишү буенча Иске Кулаткы беренче һәм икенче номерлы урта мәктәпләренең директорлары өлкә Губернаторы С. И. Морозовка махсус хат юлларга булдылар.

Киңәшмәдә шулай ук Иске Кулаткы район администрациясенең алып баручы белгече Р. Ш. Кушаев чыгыш ясады. Ул 15 июньгә Вязовый Гай авылында якташыбыз Р. Ф. Герое Рәфагать Хабибуллиның исемен йөреткән урамга тулаем асфальт салынуын белдерде.

Иске Кулаткы беренче номерлы урта мәктәбе директоры Г. В. Бәширова мәктәп территориясенә асфальт салу кирәклеген сорады.

- 2018 елда без Иске Кулаткы беренче номерлы урта мәктәбе йортында бу эшне җәелдереп җибәрәчәкбез,- дип ышандырды Р. Ш. Кушаев.

**Рөстәм АРИФУЛЛИН.**

Официальная информация

Нашему корреспонденту представилась редкая возможность провести целый рабочий день с премьер-министром РФ.



# Один день с премьером

На минувшей неделе Дмитрий Медведев провел в Ульяновске совещание, участникам которого он предложил обсудить некоторые дополнительные меры, которые необходимо принять, для того чтобы наше гражданское авиастроение могло успешно конкурировать с иностранными компаниями и на иностранных рынках, и, конечно, прежде всего у нас в стране.

### ПОСИДЕТЬ В КАБИНКЕ ЛЕТЧИКА

Перед совещанием премьер-министр осмотрел два предприятия АО «Авиастар-СП» и АО «Аэрокомпозит-Ульяновск». На первом Дмитрий Медведев подробно ознакомился с производством Ил-76МД-90А и Ил-78М-90А.

- Объем заказов военно-транспортных Ил-76МД-90А составляет 39 самолетов. Заказчику уже передано 3 машины. В настоящее время на предприятии на разных стадиях производства находится десять модернизированных Ил-76. Планируем завершить совместные испытания Ил-76МД-90А в 2019 году. Первый отечественный воздушный топливозаправщик Ил-78М-90А находится на завершающей стадии окончательной сборки. Летные испытания начнутся в 2018 году, - рассказал вице-президент по транспортной авиации Объединенной авиастроительной корпорации Алексей Рогозин.

- При этом одновременно строится первый опытный образец самолета-топливозаправщика (Ил-78М), - добавил Дмитрий Анатольевич.

Председатель правительства также поинтересовался, чем новые самолеты отличаются от стандартного Ил-76, а также сохраняются ли стеклянные кабины.

Не удержался премьер и от возможности осмотреть лайнер изнутри.

- Самое интересное - посидеть в кабинке летчика. Одни эмоции! - высказался Медведев.

### ИЗ ПРЕМЬЕРА – В СПАЙЩИКИ

На АО «АэроКомпозит-Ульяновск» Дмитрию Медведеву показали, как изготавливаются композитные крылья для МС-21, нового российского лайнера. Здесь глава Кабмина лично принял участие в управлении лазерной установкой, которая осуществляет спайку композитного крыла.

- Когда на таких предприятиях смотришь, какие самолеты выпускались и выпускаются, испытываешь чувство гордости. Тем не менее на рубеже веков наш авиапром переживал тяжелый кризис. И последнее время государство прилагает достаточно серьезные усилия, инвестируя значительные государственные средства, чтобы этот кризис преодолеть. Но впереди большая работа. Нам только предстоит полностью вернуть себе рынок. Пока мы не производили самолеты, российские перевозчики закупали иностранную технику. Сегодня парк магистральных самолетов почти на 80% состоит из зарубежных лайнеров, - обозначил проблему глава Кабмина.

По поручению правительства сейчас согласуются производственные программы самолетостроительных предприятий по обновлению парка российских авиакомпаний. Всего на поддержку самолетостроения в этом году предусмотрено около 41 млрд рублей.

- Здесь нужно избегать административного давления. Наши самолеты должны выигрывать в конкурентной борьбе. Для этого нужно совершенствовать и улучшать существующие и новые модели, - добавил Дмитрий Медведев.

По словам президента ПАО «Объединенная авиастроительная корпорация» Юрия Слюсаря, отрасль должна заниматься планированием с горизонтом 20 лет. В этот период потребность внутреннего российского рынка в пассажирских самолетах составит более 1 100 машин.

- Наиболее востребованным сегментом останутся узкофюзеляжные самолеты вместимостью от 120 кресел - мы ожидаем спрос на российском рынке в этот период порядка 710 самолетов, - отметил Юрий Слюсарь.

### МЕДВЕДЕВ ПОДДЕРЖАЛ МОРОЗОВА

Губернатор Сергей Морозов представил Дмитрию Анатольевичу проект развития альтернативной энергетики, в частности, по строительству ветрогенерирующей станции на территории Ульяновской области. Первая часть проекта уже реализуется - это ветроэлектростанция на 35 мегаватт, которую строит компания «Фортум». В конце года она будет введена в эксплуатацию.

В дальнейшем регион планирует построить еще таких ветропарков до 500 мегаватт, для того чтобы увеличить долю возобновляемой энергетики в общем энергобалансе области. Цель не только поставить ветропарки для генерации, но и развивать новую отрасль - производство комплектующих для ветрогенераторов. Согласно условиям федерального правительства, необходимо локализовать объем производства и в конечном итоге довести производство ветрогенераторов в России до 70 процентов. Для этого региональные власти планируют задействовать площадку «АэроКомпозита», который производит композитные запчасти для самолетов, а вскоре и композитные лопасти для ветрогенераторов.

В ходе визита на «Аэрокомпозит» премьер Дмитрий Медведев поддержал предложение Сергея Морозова расширить меры поддержки российских и иностранных инвесторов, готовых вкладывать средства в развитие ветроэнергетики. Кроме того, Дмитрий Медведев одобрил намерение ульяновского



индустриального парка получить статус федеральной особой экономической зоны промышленно-производственного типа. Это означает, что регион сможет предоставлять потенциальным инвесторам дополнительные налоговые и таможенные преференции, а это, в свою очередь, позволит Ульяновской области проводить еще более эффективную инвестиционную политику.

# Электронная соцпомощь

**Андрей Корчагин**

Социальные продовольственные карты были внедрены в Ульяновске осенью 2015 года.

Получить этот вид социальной поддержки могут ульяновцы, которые оказались в трудной жизненной ситуации и чей доход ниже величины прожиточного минимума, установленного в регионе.

Каждому владельцу социальной карты ежемесячно зачисляется одна тысяча рублей, на которую можно приобретать определенный список продуктов в ульяновских магазинах «Победа». Только в прошлом году карты получили более 1500 жителей регионального центра. На оказание этого вида помощи из областного бюджета было выделено свыше четырех миллионов рублей.

И вот теперь география действия карт расширяется. Теперь получить бесплатные продукты смогут не только нуждающиеся жители Ульяновска, но и те, кто проживает в других муниципальных образованиях. Социальные карты будут действовать не только в магазинах «Победа», которые есть исключительно в Ульяновске, но и в магазинах «Пятерочка». Около 100 универсамов этой торговой сети работают практически во всех населенных пунктах области.

Включение в процесс оказания соцпомощи магазинов «Пятерочка» - результат соглашения о намерениях, подписанного губернатором Сергеем Морозовым и директором по работе с государственными органами власти X5 Retail Group Станиславом Наумовым. Документ, предусматривающий оплату продуктов питания электронными социальными продовольственными картами в магазинах "Пятерочка" во всех муниципалитетах области, подписан 8 июня в ходе II Форума социальных инноваций, который завершается сегодня в Красногорске.

- Опыт пилотной реализации проекта показал его высокую эффективность и востребованность, - отметил Сергей Морозов. - Поэтому встал вопрос о распространении практики на всю территорию региона. Одной из первых на данную инициативу откликнулась компания X5 Retail Group, создавшая в области развитую сеть магазинов «Пятерочка». Теперь государственная продовольственная помощь будет доступна практически всем жителям, в ней нуждающимся.

В ближайшие три года на оказание адресной помощи будет выделено порядка 180 миллионов рублей из облбюджета. Это позволит выдать 30 тысяч продовольственных социальных карт.

Проект, как и вся социальная политика области, получил высокую оценку федеральных экспертов.

- Ульяновская область - это действительно регион социальных инноваций, где постоянно появляется что-то новое в социальной сфере, - отметила директор автономной некоммерческой организации «Агентство социальной информации», член Общественной палаты РФ Елена Тополева-Солдунова. - Достижения региона очевидны. Это высокая степень защиты нуждающихся, в том числе семей с детьми, и содействие развитию благотворительности, волонтерства, некоммерческих организаций... При этом очень важно, что область не останавливается на достигнутом. И новая инициатива - введение продуктовых социальных карт - это тоже проявление внимания и поддержки властей. Я бы назвала Ульяновскую область регионом заботы о людях. И мне особенно отрадно, что активно развивается тема выхода некоммерческих организаций на рынок социальных услуг. В том числе и на муниципальном уровне. И мы надеемся, что скоро узнаем о новых прорывах и инновациях.

# Зарплату ульяновским бюджетникам повысят на 38%



Зарплату ульяновским бюджетникам будут повышать в три этапа. Об этом глава региона Сергей Морозов заявил в ходе рабочей встречи с премьер-министром РФ Дмитрием Медведевым, сообщает ИА REGNUM.

«Буквально на этой неделе мы окончательно определились с выполнением вашего поручения по росту заработной платы для работников культуры, здравоохранения, начиная от врачей и заканчивая младшим медицинским персоналом, для работников образования и органов социальной защиты», - заявил Морозов. По его словам, общий рост повышения заработной платы составляет по разным категориям от 15 до 38%.

«Вы говорили о том, что мы должны в условиях сегодняшней некоторой финансовой нестабильности проработать вопрос о повышении заработной платы начиная с 1 апреля. Мы приняли решение в три этапа повысить заработную плату, - уточнил Морозов, обращаясь к Медведеву. - С 1 апреля этого года - проведем сейчас соответствующие перерасчеты и выплатим в том числе и к отпускным. Вторая - с 1 июля. И еще одно повышение будет ориентировочно с 1 октября. Кроме этого, принято решение о существенном повышении (даже больше, чем сейчас) в течение I квартала 2018 года».



# 18 июнь – Медицина хезмәткәрләре көне

# Ак халатлы фәрештә

*Чак кына авырсак та, сәламәтлегемне кайтар, дип, Аллаһка ялварабыз һәм терелүгә өмет итәбез. Аллаһы Тәгалә безгә ярдәмгә ак халатлы кешеләр җибәрә. Аларның күңеленә кешеләрне ярату һәм мәрхәмәтлелек иңдерә. «Кешеләрне яратмасаң, аларны дәвалап булмый», - диләр Иске Кулатки район больницасының шәфкать ияләре.*

Сызран шәһәренең медицина училищесын тәмамлагач, Рәфика әтисе Шикюр Исмәгыйлович белән әнисе Равза Биляловна туып үскән Иске Кулатки районына эшкә кайта һәм 1977 елдан райондашлары сәламәтлеге сагында тора. Аны ашыгыч ярдәм бүлегенә фельдшер итеп эшкә билгелиләр. Җитез, акыллы кызны Яңа Яндука егете Рәшит Мәзит улы Надршин сизеп ала. Ике арада мәхәббәт уты кабына, озакламый гөрләтеп туйны да уйныйлар. Яшь киленне үз авылына тарта егет, больница администрациясе дә каршы төшми. Яңа Яндука авылының гөрләп торган чагы, фельдшер – акушерлык пункты төзелгән, Рәфиканың һөнәре дә туры килә, азрак тәҗрибә дә туплап өлгергән инде. Авыл халкы күләч йөзле, тырыш белгечне бик тиз үз итәләр. Чөнки ул вакыт белән санашмый, төнме – көнме авырулар янына чаба, кирәк икән фермага менеп анда да медицина хезмәте күрсәтеп кайта.

Фельдшер буларак, авыл халкына күрсәткән игелекләре санап бетергесез. Авыруларны дәвалап кына түгел, үлемнән коткарган чагы да аз булмый аның. Салкын акыл һәм үзенә бик нык ышану кирәк, чын йөрәктән эшенә бирелгән кеше генә булдыра ала моны. «Чираттагы уколны ясарга баргач, зарыгып каршы алган авыруларның өмет тулы күзләрен әле дә оныта алмыйм», - ди Рәфика яшьлек елларын искә алганда.

Аннары гаиләне тулыландырып кызы Лилияне туа, тик ул чакта бала тотып өйдә озак утыра торган заман түгел иде шул, бер яше тулар тулмас ук ясле - бакчага биреп эшкә чыга. Надршиннар гаиләсе инде ул чакта Иске Кулатки районы үзәгенә күчәләр. Рәшит Мәзитовичка тырышып эшләгән өчен "Иске Кулаткы" совхозы яшь гаиләгә дип квартира бирә. Рәфика Шикюр кызын район больницасының балалар бүлегенә медицина туташы итеп эшкә күчерәләр. 1980 нче елларда әлеге XXI гасырдагы кебек 2-3 бала тумый, ул вакытта елына 20-25 бала дөньяга аваз сала иде. Авыраган балаларны да өйдә дәвалап торырга әниләренең вакыты юк, больницада дәваланырга салалар. Ике – өч табиб – педиатр эшли, алар билгеләгән процедураларны үтәп кенә өлгер. "Рәфика апаның кулы укол куйганда бердә авыртмый", - дияләр иде балалар, аның дежур көнен көтеп торалар.



Җылы карашы, тәмле сүзе белән дә дәвалый шәфкать туташы. Борынгылар да: "һөнәр кием түгел, ошамаса салып атып булмый", – дип әйткәннәр. Ә бит чынлап та, кешенең ярты гомере эштә үтә. Яраткан эшендә гомерең шатлыклы, данлыклы була.

Балалар бүлегендә биш ел эшләгәннән соң Рәфика Шикюровнаны терапия бүлегенә күчерәләр, ә аннары хирургия бүлегендә эшен дәвам итә. Кайсы бер төннәрдә күз йомарга түгел, утырып бер минут ял итәргә дә вакыт булмаган чаклары еш була. Кеше гомере өчен көрәш алып барганда табиб янында алар, ак халатлы фәрештәләр булалар. Ашыгыч ярдәм кирәк булганда, төн уртасында да, бәйрәмнәрдә дә авыру янында аяк өстә вакыт үткәрәләр; кая уколын сала, кая яхшы сүзе белән дәвалый. Профессия буенча үсеш юлында күп баскычларны атлый Рәфика ханым. Тырыш, булдыклы Р.Ш. Надршинаны өлкән шәфкать туташы итеп билгелиләр. Хезмәттәшләре, авырулар арасында да хөрмәт яулый ул. Миңа калса, чын шәфкать туташы - тумыштан килгән сәләт иясе. Шул сәләт иясе кырык елга якын район больницасында үз һөнәренә тугры булып кала. Кешеләргә күрсәткән ярдәме турында әйтеп кенә бетереп булмый. Хезмәтендә абруй казанган ханым - өйдә дә уңган хуҗабикә; өендә аның һәрвакыт тәртип. Рәфика Шикюр кызы, тормыш иптәше Рәшит Мәзит улы белән бергә, Лилия кызларын һәм Рафаэль улларын яратып-сөеп үстергәннәр, ныклы белем биргәннәр. Кызлары Лилия белән кияүләре Илдар бүген Самара шәһәрендә хезмәт итәләр. Әти – әниләрен куандырып Эмилия белән Диляра исемле сөйкемле оныклар бүләк иткәннәр. Уллары Рафаэль да аларның шатлыгы – таянычы, Самара шәһәрендә хезмәт итә, әлегә гаиләсен кормаган. Рәфика Шикюр кызы оныкларын тәрбияләшергә дә вакыт таба. Кышка яшелчәләрдән тәмле-тәмле салатларясый, камыр ашларын да уңдыра. Тиздән тормыш иптәше Рәшит Мәзитович белән бергә тормыш корып яшәүләренә дә 40 ел тула инде, якут (рубин) туйларын билгеләп үтәчәкләр. Бер – берсен хөрмәт итеп яшәгәнгә күрә, вакытның үткәнен дә сизми калганнар Надршиннар, күңелләре әле дә яшь, әле дә мәхәббәтле үзләре.

Рәфика ул тугры хатын, яраткан әни, сөекле әбекәй генә түгел, әле кайгыртучан бала да. Аның әнисе Равза Биляловна бүген дә кызының кайгыртучанлыгына, мөлаем, йомшак карашына төренеп яши. Надршиннар әниләренә гел игътибарлы булып, Сызран шәһәренә аның янына барып, ярдәмләшеп торалар. Рәфика ханым бүген хезмәт иткән хирургия бүлегендә кирәкле, зур тәҗрибәгә ия булган белгеч.

- Без, хирургия бүлеге хезмәткәрләре, Рәфика апабызны хөрмәт итәбез, олылыйбыз. Аның озын - озак, остазыбыз булуын, арабызда хезмәт итүен телибез. Исәнлек - саулык, ак бәхетләр, балаларының шатлыкларына гына төренеп яшәргә насыйп булсын иде үзләренә. Олы юбилееӊ белән Рәфика Шикюровна, - дип язганнар хезмәттәшләре.

"Гомерем заяга узмады, бер генә мизгелгә дә бу һөнәрне сайлаганыма үкенмәдем," - ди хезмәт ветераны, шәфкать туташыбыз. Эшен югары бәялиләр аның, исәпсез мактау грамота-дипломнары да шул хакта сөйли. Райондашларыннан эшләгән игелекләре өчен рәхмәт сүзләре генә ишетеп яшәргә язсын иде Рәфика ханымга.

Исән-имин, бәхетле һәм озын гомерле булыгыз, ак халатлы фәрештә!

**Майзә МАСИЕВА.**

# Яшәү яме кулларыгызда

Тормышның ямен, яшәүнең тәмен исән – сау чакта гына аңлыйсың. Авырап киткәч күзеңә бер нәрсә дә күренми икән. Шәфкать туташларына рәхмәт сүзләре белән язмаларны еш кына район газетасында укып киләм. Бигрәк мактыйлар инде, дип көрсенеп тә куя идем кайбер вакыт. Ә үзем шулар кулына, бик авыр хәлдә дучар булгач, чынлап та фәрештәләр икән үзләре, дип инандым.

Кан басымы югарыга күтәрелеп, йөрәк авырта башлагач, хәл бигрәк начарлана. Иске Кулатки район больницасының терапия бүлегендә хезмәт итүче табиб Гүзәл Асфетовна Аюпованың карамагына эләктем. Ул тиз арада тиешле дәвалауны билгеләде, үземне ягымлы сүзләре белән тынычландырды. Ә шәфкать туташлары Г.М. Сәләева, Г.И. Курамшина тиешле процедураларны, даруларны рәсмиләштерделәр. Җитез, өлгер медицина хезмәткәрләре Г.Р. Мохамедова, Г.М. Хәкимова, И.К. Хамзина, Г.А. Исмаилова йомшак куллары белән, төгәл хәрәкәтләр ясап уколлар, системаларны куйдылар. Әлеге терапия бүлегендә авырулар бик күп дәвалана, дежурга килгән шәфкать туташына киеренке рәвештә эш алып барырга туры килә. Шулай булса да авыруларга бер дә игътибарсыз булганнарын сизмәдем.

Ашатучы Г.З. Кузәева да, санитаркалар Г.Я. Амирова, Г.Р. Тимушева, А.С. Җәмәлетдинова, З.Р. Сәләйманова үз эшләрен пөхтә итеп башкаралар.

Менә шушы барлык медицина хезмәткәрләренә рәхмәт сүзләре җиткерәсе килә. Эшләрендә уңышлар, сабырлык, тынычлык телибез. Бигрәк тә табибыбыз Гүзәл ханым Аюповага олы ихтирамыбыз. Озын – озак, исән – сау хезмәт итеп, райондашларыбызны шатландырып, яшәүгә дәрт өстәп торсын иде.

**Камил ЗӘЛКӘРНӘЕВ,**
**Иске Атлаш.**
**Фәрит РАМАЗАНОВ,**
**Иске Кулаткы.**
**Ринат НАСЫЙРОВ,**
**Мосеевка авылы.**

# Рәхмәтем чиксез, хөрмәтем зур

Яшел наратлар һәм ак каеннар арасында урнашкан Иске Атлаш авылы хастаханәсендә мәрхәмәтле, гыйлемле һәм иң матур медицина хезмәткәрләре хезмәт итә. Тормышның әчесен дә, шатлыкларын, югалтуларын, хәсрәтләрен дә татыган тыл хезмәтчәне, 50 елга якын тол хатын булып яшәүче – сөекле әнием Нәгыймә Ризван кызын алар күп тапкыр инде үлем тырнагыннан коткарып калдылар. Хастаханә җитәкчесе Румия Алимовна Муллабаева, шәфкать туташлары Римма Нәзировна Сәгадәтова, Гүзәл Рифат кызы Уразлина, Иркә Әхмәтша кызы Рафикова, Алия Али кызы Бочкарева көнне төнгә ялгап авыраган әнием янында булып, ярдәм күрсәттеләр. Шулай ук санитаркалар Рита Байбикова, Луиза Давыдова, Әлфия Ямашева һәрвакыт ачык йөзләре, йомшак сүзләре белән авыраган авылдашларының күңелләрен күтәрәләр. Иртә димиләр, кич димиләр – авыру янына барып ярдәм күрсәтәләр, аның хәле яхшырмыйча өйләренә кайтып китмиләр. Дарулар белән генә түгел, яхшы сүзләре, җылы карашлары белән дә дәвалыйлар.

Бу ак халатлы фәрештәләрне якындагы авылларда да белмәгән кеше юктыр, дип әйтсәм дә, бик дөрес булыр. Шундый изге җаннарның берсе - мөлаем йөзле Гүзәл Уразлина. Көнме, төнме ул палаталарга кереп авыруларның хәлләрен белә, кирәк ярдәмне күрсәтә, игътибарлылыгы белән яшәү дәрте өсти. Ул тыйнак, кайнар йөрәкле кеше. Авыруның савыгу шатлыгы – табибларга буган зур хөрмәт.

**Гүзәл, Гүзәлия!**

*Авырулар сине хөрмәтләп*
*Нур сибүче кояшыбыз*
*диләр.*
*Мәрхәмәтле булганга*
*Яше-карты сиңа баш ия.*
*Гүзәлия, Гүзәлия!*
*Авыруларга дәва, сөенеч,*
*Изгелегең, саф тавышың-*
*Югалтма шул*
*матурлыкны*
*Бу Ходай биргән*
*табышың!*

Хастаханәдә хезмәт итүче табибларга, шәфкать туташларына, санитаркаларга, аш осталарына, чисталык сагында торучыларга, барчасына да олы рәхмәтемне белдерәм.

Әниемнең хәле авыр вакытта ярдәм итүче күршеләремә Вәльшина Фәүзиягә, Ахмерова Кәмиләгә, Хәбибуллина Саниягә олы рәхмәт сүзләремне җиткерәм. Ходай Сезгә кояшлы, матур көннәр, исәнлек-саулык, кайгы-хәсрәтсез, якты, тыныч еллар, бетмәс бәхетләр бүләк итсен. Менә шундый яхшы, үрнәккә куярлык кешеләр – авылымның горурлыгы.

**Олы хөрмәт белән**
**Рәфика Шәрипова.**

Дин, әһлак һәм вөҗдан иреге

# Ифтар мәҗлесендә

5 июнь кичендә, Иске Кулаткы эшчеләр поселогының “Гани” мәчетендә, ифтар мәҗлесе булып узды. Бу изге чарага бихисап мөселманнар килгәннәр иде.

Анда Иске Кулаткы район администрациясе Башлыгы И.А. Аблязов, Ульяновск өлкәсенең баш ахуны Илдар хаҗи Сәфиуллин, якташыбыз, Самара мәчетенең баш имамы Иршат хәзрәт Сафин һәм башкалар олы кунаклар буларак катнаштылар.

Мәҗелес башланыр алдыннан Иршат хәзрәт Сафин мөселманнарга вәгазьләр сөйләде. Ул үзенең чыгышында хәзерге заманда динебезне үстерү өчен зур мөмкинлекләр бирелүе турында ассызыклап, мөселманнарны дини йолаларыбызны башкарырга чакырды.

Аннан соң Илдар хаҗи Сәфиуллин мөселманнарга Ходай Тәгалә каршында ураза тотуның әһәмиятлелеге турында чыгыш ясады. Ул шулай ук дин, әхлак темасына эчтәлекле вәгазьләр дә сөйләде.

“Гани” мәчетенең баш имамы Рәхимҗан хәзрәт Фәйзуллин изге чарага килгән мөселманнарга һәм кунакларга олы рәхмәтләрен белдерде һәм “Гани” мәчетен төзүдә катнашучы мөселманнарга, район Башлыгы Э. Ә. Ганеевка, элеккеге имамнарга, әрвахларга догалар кылдырды.



Әлеге кичәдә Ульяновск шәһәренең дин әһеле Марат хәзрәт тә вәгазьләр сөйләде.

Аннан соң мөселманнар ифтар кылып, намазын укыдылар. Ифтар намазыннан соң бу мәхәлләнең хатын-кызларына аш - су хәзерләгәннәре өчен олы рәхмәтләр белдереп, мәҗлес ашлары да тәм иттеләр.

**Рөстәм АРИФУЛЛИН.**

# Кешелеклелекләре сокландырды

Мин Иске Кулаткыда эшләп торучы малтабарларыбызның кешелекле, ярдәмчел булуларына сокланып һәм шатланып язам. Өемдә азрак ремонт ясарга башлагач “И.П. Рамазанов” кибетенә мөрәҗәгать иттем. Бик игътибарлы булып, ачык йөз белән каршы алдылар. Төзү материалларын үзләре үк китереп йортыма куйдылар, бер дә авырлык күрмәдем. Фәһим Мөнир улы Рамазанов та, сатучылар да, эшчеләре дә берни белән санашмыйча, тиз арада барлык тиешле хезмәтләрне күрсәттеләр. Мин аларга барчасына яраткан газетам аша рәхмәт белдерәм. Һәрчак шундый мәрхәмәтле, игътибарлы булып калсыннар иде.

**Рәхимә КИЧИМОВА.**
**Иске Кулаткы.**

Бәйрәм кайтавазы

# Балаларны берләштерде Сабантуй



Иске Кулаткы “Гөлчәчәк” балалар бакчасында балаларны туган телгә өйрәтү, милли йолаларыбызга нигезләнеп тәрбияләү, милли рух сеңдерү, төрле чаралар әзерләү – төп максатлар итеп куелган. Бакча коллективы һәр бәйрәмне бик җентекләп әзерли. Әлеге чараларны балалар да, әти - әниләр дә мавыгып көтә.

8 июнь көнне “Гөлчәчәк”тә балалар Сабан туе гөрләде. Көн иртәдән үк кояшлы, ямьле иде. Бакча тирәсе, Сабантуй мәйданчыгы, сәхнә матур итеп бизәлгән. Бәйрәмгә балалар, аларның тәрбиячеләре, әти - әниләре, район җитәкчеләре җыелган иде. Милли киемнәрдән киенгән нәниләр кунакларны чәкчәк белән каршы алдылар.

Искиткеч матур киемнәргә киенгән балалар “Сабантуй” фольклор күренеше белән бәйрәмне ачып җибәрделәр. Алар мәйданчыкка Сабантуй әләмен һәм флагын күтәреп керделәр.

Бакча мөдире Л.Ф. Богданова кунакларны сәламләп, милли бәйрәм белән тәбрикләде. Милли йолаларыбызны алда да саклап калып, яшь буынга мирас итеп кирәклеге турында сөйләде.

Район Башлыгы урынбасары М.М. Бәширов та бәйрәмгә килүчеләргә матур теләкләрен юллап, мөһим чараның дәвамлы булуын теләде.

Балалар Сабан туе аеруча җанлы, җыр-биюле, күңелле иде. Нәниләрнең чыгышларын кунаклар сөенеп карадылар, кәефләрен күтәрделәр.

Балалар бер-берсен уздырып, төрле бәйгеләрдә катнашып, җитезлектә көч сынаштылар. Уенчык атларга атланып узыштылар, кашыкка йомырка куеп йөгерделәр, көянтәчиләк тотып ярыштылар, капчык киеп йөгерделәр, канат тарттылар. Ә инде бәйрәмгә килгән әкият геройлары - Шүрәле һәм Убырлы Карчык балаларга дәрт биреп тордылар һәм алар белән бергә күңел ачтылар.

Балалардан соң ярышларга әти-әниләр чыктылар. Аларның чүлмәк ватуы, катыктан акча эзләп табуы - бәйрәмне тагын да җанландырып җибәрде. Уеннарда катнашучылар бүләксез калмады. Бәйрәмдә һәрбер балага татлылар тапшырылды.



Сабан туйның иң кызыклы һәм кызган мизгеле – көрәш булды. Көрәштә катнашырга теләүче малайлар саны да күп иде. Көч сынашуны түземсезлек белән көтте алар. “Абсолют батыр” исемен Тимур Юсупов яулады. Индивидуаль эшмәкәр И.Р. Ибраһимова һәм элеккеге тәрбияләнүче З.Ф. Байбикова бүләкләр алуда спонсорлык ярдәм күрсәттеләр.

Килгән кунаклар бәйрәмне бик ошатты. Алар җылы каршы алу, җәй буена җитәрлек яхшы кәеф бүләк иткән өчен бакча коллективына рәхмәтләрен ирештерделәр.

Әлеге Сабантуй - балалар бәйрәме генә түгел, дуслык, тәҗрибә уртаклашу чарасы да. Тәрбияләнүчеләр татар милли бәйрәме белән таныштылар, милли уеннар аша сәламәтлекләрен ныгыттылар, милли бәйрәмгә карата хөрмәт хисләре уяттылар. Бу истәлекле көн, бәхетле мизгелләр һәркемнең күңеленә кереп калды.

**Әлфия ЯФАРОВА.**

Юмореска

# Современный Мәнсура



Авылның очында, ике катлы коттеджда яшәүче, “Озын Мәнсура” бозау кадәрле эте белән чик сакчысы кебек капка төбенә чыкты да, сарыкларын ияртеп баручы Инсян картка:

- Ал сарыкларыңны! Өй каршымнан узмасыннар, капка алдымны пычраталар! Югыйсә этемнән талатырмын үзләрен, – дип җикеренде.

- Мәнсура, сеңелем, без бит авылда яшибез, элек – электән һәр өй каршыннан көтү-көтү булып сыеры да, сарыгы да, кәҗәсе дә узды һәм беркем дә моңа тыгызланмады. - Ник син алай тупас кылынасың? - дип гаҗәпләнде Инсян карт.

- Ул элек шулай булгандыр, ә без хәзер современный авылда, мал-туары юк булган авылда, культурный гына яшәргә тырышабыз, - диде русчалатып “Озын Мәнсура” этен сыйпап.

- Современный авыл, Современный Мәнсура, - дип үзалдына сөйләнеп китеп барды Инсян карт үз урамындагы бу хәлне башына сыйдырмыйча.

- Бу бит шофер Маннур кызы шулай кылына. Оныткан, оныткан бит үзенең катык ашап үскән чакларын. Катык ашап үскән дә, ай-һай үзгәргән Мәнсура.

Мәнсура гына түгел, авылның да элеккеге йөзе кайдадыр: үзгәрә, югала бара



бугай. Элек елларда авылда сыер, сарык асрамый торган кешеләрдән көлсәләр, хәзер “современный Мәнсуралар” мал-туар асраучылардан көлә башладылар. Бу авылның асты өскә килде дигәнне аңлата түгелме соң?!

Бусы бер хәл, әле моның янына башкаларын да тезештерергә була бит. Кайберәүләр авыл морҗасыннан чыккан төтенен дә яратмый башладылар инде. Соңгы вакытларда Инсян картның уң яктагы күршеләре: “Бабай мунчаңның төтене авызыбызга керә, хәзер мунчасыз да яшәп була бит”, – дип йомшак кына аңа душ кабинасын алуны тәкъдим иттеләр.

Авыл очында “Озын Мәнсурага” - сарыклар, уң як күршегә - мунча төтене, сул як күршегә әтәч кычкырганы ярамаса, Алла белсен, гомере буе авылны үз иткән Инсян картка киләчәктә ничек яшәргәдер?

**Рөстәм АРИФУЛЛИН.**
**Иске Кулаткы.**

Редакция хат алды

# Рәхмәтебезне кабул итегез

1 июнь – Халыкара балаларны яклау көне уңаеннан Иске Кулаткы «Парус Надежды» инвалид балаларны реабилитацияләү үзәгендә дә матур бәйрәм чарасы узды. Үзәктә эшләүче белгечләр З. Н. Аксенова, Ф. А. Бимеева, Д. З. Сәбитова, Г. Х. Исмаилова ата-аналарны һәм балаларны көләч йөзләре белән каршы алдылар. Бәйрәм белән тәбрикләп, балаларга изге теләкләрен юлладылар. Мавыктыргыч бәйрәм программасы, кызыклы конкурслар, җыр-биюләр белән үрелеп барды.



Бәйрәм бик күңелле итеп оештырылган, балаларга да бик ошады. Балаларыбызга менә шундый шатлык биргән, бәйрәмне оештырган “Парус Надежды” үзәге белгечләренә, биредә катнашкан барлык әниләр һәм балалар исеменнән рәхмәт әйтәсем килә. Олы рәхмәт сүзләребезне үзәгебезгә даими спонсорлык ярдәм күрсәтүче район Башлыгы Э. Ә. Ганеевка һәм район администрациясе Башлыгының кеше потенциалын үстерү буенча урынбасары В. А. Деникаевага җиткерәсебез килә. Аларның кайгыртучанлыгы белән балаларыбыз бер бәйрәмдә дә игътибарсыз калмый, һәрвакыт бүләкләре белән куандыралар. Ә менә күптән түгел генә үзәкнең бүлмәләренә косметик ремонт ясалды һәм яңа заманча ишек куелды. Барлык чыгымнарны да Э. Ә. Ганеев үз өстенә алды. Э. Ә. Ганеевка һәм В. А. Деникаевага үзәкнең белгечләре, барлык ата-аналар һәм балаларыбыз исеменнән изге рәхмәт сүзләребезне җиткерәбез һәм авыр хезмәтләрендә уңышлар теләп калабыз.

**Лилия ЮНУСОВА.**
**Иске Кулаткы.**